МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.11.2022 г. Казань № под-2019/22

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә укытуга рөхсәт бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 маддәсендәге 1 пункты нигезендә һәм гражданнарның һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез гомуми белем алуга хокукларын тәэмин итү максатларында, б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына балаларны башлангыч гомуми белем бирүнең укыту программалары буенча кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә укыту өчен кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә уку елының 1 сентябренә 6 яшь һәм 6 ай тулмаган яисә 8 яшьтән өлкәнрәк яшьтә булган балаларны башлангыч гомуми белем бирүнең укыту программалары буенча укырга кабул иткәндә әлеге Тәртип белән эш итәргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаментының аналитик, мәгълүмати һәм оештыру тәэминаты бүлегенә (Л.И. Саубанова) әлеге боерыкның Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвен алуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары – мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе Р.Г. Мөҗиповка йөкләргә.

Министр И.Г. Һадиуллин

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән
министрлыгы боерыгы белән
расланды
23.11.2022 № под-2019/22

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә укытуга рөхсәт бирү
ТӘРТИБЕ

1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына балаларны кабул итүгә рөхсәт бирү, башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә укытуга рөхсәт бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан Министрлык буйсынуындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына (алга таба – гомуми белем бирү оешмалары) башлангыч белем бирү программалары буенча 6 яшь һәм 6 айдан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны укытуга рөхсәт бирү тәртибен, шулай ук министрлыкның һәм гомуми белем бирү оешмаларының үзара хезмәттәшлек тәртибен билгели.

1.2. Тәртип түбәндәге норматив хокукый документлар нигезендә эшләнгән:

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы;

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 02 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 елның 08 маендагы 287 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турында нигезләмә;

гражданнарга башлангыч гомуми белем бирүне оештыруны регламентлаштыра торган башка норматив хокукый актлар белән.

1.3. Башлангыч гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмаларына балаларны кабул итүгә рөхсәт бирү турындагы мәсьәлә башлангыч гомуми белем бирү программаларын кечерәк яшьтә (алты яшь һәм алты айдан да иртәрәк) яисә өлкәнрәк яшьтә (сигез яшьтән өлкәнрәк) гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү мәсьәләсе буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау өчен Министрлык комиссиясе тарафыннан карала (алга таба – Комиссия).

1.4. Комиссиянең шәхси составы Министрлык боерыгы белән раслана.

2. Эшне оештыру.

2.1. Балаларны кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә башлангыч гомуми белем бирүнең укыту программалары буенча укырга рөхсәт алу өчен баланың ата-аналарына (законлы вәкилләренә), түбәндәге документларны кушымта буларак өстәп, Министрлыкка гариза белән мөрәҗәгать итәргә кирәк (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта, әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта):

ата-ананың (законлы вәкилнең) шәхесен раслый торган паспорт;

бала туу турында таныклыкның күчермәсе;

таратылу өчен рөхсәт ителгән ата-ананың шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы (әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта);

законлы вәкил балигъ булмаган баланың опекуны яисә попечителе булса, опека яисә попечительлек урнаштыруны раслый торган документның күчермәсе;

сәламәтлек ягыннан белем алу өчен каршылыклар булмавын раслый торган «Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү учреждениеләре, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре, балалар йортлары һәм интернат мәктәпләре өчен баланың медицина картасы» 026/у-2000 номерлы форма (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Мәгариф учреждениеләре өчен баланың медицина картасын раслау турында» 2000 елның 3 июлендәге 241 номерлы боерыгы).

Баланың чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат булган ата-аналары (законлы вәкилләре) өстәмә рәвештә гариза бирүчеләрнең туганлыгын (яисә бала хокукларын тәкъдим итүнең законлылыгын) раслый торган документ һәм баланың Россия Федерациясендә булу хокукын раслый торган документ күрсәтәләр. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар барлык документларны рус телендә яисә билгеләнгән тәртиптә расланган рус теленә тәрҗемә белән бергә бирәләр.

Гаризаны өйрәнгәндә, Комиссия ата-ана (законлы вәкил) тарафыннан тәкъдим ителгән башка материалларны (балаларны башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укырга кабул итү турында мәгариф идарәсенең муниципаль органнары карарларын һәм тәкъдимнәрен) исәпкә ала.

2.2. Гомуми белем бирү оешмаларына кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә кабул итү турында мәсьәләне вакытында хәл итү максатында, гариза Министрлыкка уку елы башланырга 10 көннән дә соңга калмыйча тәкъдим ителә.

2.3. Гаризаларны теркәү урыны булып Министрлыкның мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты тора, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: 420044, Казан шәһәре, Ямашев урамы, 36 йорт, 401 каб (кәгазьдә) яисә Departament.Nadzora@tatar.ru электрон почтасы.

2.4. Килепирешкән гаризалар «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Гариза тапшырылган көннән алып 10 көн эчендә карала.

Алты яшь һәм алты айга тулмаган балаларны, шулай ук 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны 1 сыйныфка кабул итү турында сорауларны караганда, Комиссия, бала белән әңгәмә үткәрә, гомуми үсеш дәрәҗәсен (сөйләм булмаган кайбер функцияләрнең тиешле дәрәҗәдә үсешен, телдән сөйләм үсеш дәрәҗәсен, санауга кадәр булган интуитив күзаллауларның булуын һ.б.) билгели.

Сигез яшьтән өлкәнрәк балалар өчен закон белән билгеләнгән срокларда

1 сыйныфка керә алмауның сәбәбе аныклана, медицина учреждениеләре белгечләренең тәкъдимнәре карала. Комиссия балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссиягә мондый очраклар турында хәбәр итә.

Комиссия баланың төрле фәннәр буенча белем дәрәҗәсен ачыклауга юнәлтелгән тестлар үткәрми.

Баланың уку урынын ата-аналар (законлы вәкилләр) үзләре билгели.

Комиссия исәпкә алынырга тиешле түбәндәге документларны алып бара, алар ел дәвамында саклана:

ата-ана (законлы вәкил) гаризасы һәм аңа тәкъдим ителгән документлар;

комиссия карарлары протоколлары;

гаризаларны теркәү журналы.

2.5. Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасын карау нәтиҗәсе булып ике карарның берсен кабул итү тора:

гомуми белем бирү оешмасына кабул итүгә рөхсәт;

гомуми белем бирү оешмасына кабул итүгә рөхсәт бирүдән баш тарту, шул исәптән документлар комплекты тулы булмау сәбәпле.

Документларны кабат тапшыру киләсе календарь елның 1 мартыннан 20 августына кадәр гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2.6. Комиссиянең составы түбәндәгечә:

Министрлыкның вазыйфаи заты – комиссия рәисе;

Министрлыкның вазыйфаи заты – комиссия рәисе урынбасары;

комиссия сәркатибе;

Министрлык боерыгы белән расланган, педагогик яисә медицина белеме булган башка белгечләр.

2.7. Комиссия карарны Комиссия әгъзаларының яртысы булганда кабул итә. Комиссия әгъзаларының күпчелеге тавыш биргән очракта, Комиссия карары кабул ителгән дип санала. Тавыш саны тигез булганда, Комиссия Рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

2.8. Балаларны кечерәк яки өлкәнрәк яшьтә башлангыч гомуми белем бирүнең укыту программалары буенча белем алуга рөхсәт бирү йомгаклары буенча мөрәҗәгать итүчегә баланы гомуми белем бирү оешмасына кабул итү рөхсәте белән Комиссия утырышы беркетмәсенең таныкланган күчермәсе җибәрелә (әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта). Беркетмәне рәсмиләштерү һәм юллау срогы – өч эш көне.

2.9. Алты яшь һәм алты ай тулмаган баланың гомуми белем бирү оешмасына керергә әзерлеге булмаган очракта, Комиссия ата-аналарга (законлы вәкилләренә) мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының әзерлек төркеменә йөрергә һәм киләсе уку елында гомуми белем бирү оешмасының 1 сыйныфына укырга керергә тәкъдим итә.

2.10. Кече яшьтә яисә соңрак яшьтә балаларны башлангыч гомуми белем бирүнең укыту программалары буенча укырга кабул итү турында комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе гомуми белем бирү оешмаларының электрон адресына җибәрелә.

Гомуми белем бирү оешмалары югарыда күрсәтелгән балаларны законлы һәм гомуми белем бирү оешмасының расланган тиешле кабул итү кагыйдәләре нигезендә беренче сыйныфка кабул итәләр.

2.11. Гомуми белем бирү оешмаларына кабул итүгә рөхсәт бирүдән баш тартканда, мөрәҗәгать итүчегә кире кагу турында мотивлы хәбәр җибәрелә (әлеге Тәртипкә 5 нче кушымта).

2.12. Башлангыч гомуми белем бирүнең укыту программалары буенча белем алуга рөхсәт алуда Комиссия түбәндәге очракларда баш тарта:

баланың атасы яисә анасы (законлы вәкиле) булмаган затның мөрәҗәгате;

белешмәдә күрсәтелгән башлангыч гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасында кече яшьтә яисә соңрак яшьтә белем алуга комачаулаучы медицина күрсәткечләре булу;

әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулы комплекты булмау;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр, документлар бирү.

2.13. Комиссия утырышлары көндезге форматта, шулай ук видеоконференцэлемтә кулланып үткәрелә.

2.14. Балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укытуга рөхсәт бирелгән очракта, Министрлык бу хакта балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика (муниципаль) комиссиясенә хәбәр итә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә укытуга рөхсәт бирү тәртибенә

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына балаларны кабул итүгә рөхсәт алуга, кечерәк яшьтә гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укытуга

гариза формасы

Татарстан Республикасы

Мәгариф һәм фән министрына

___________________________________

Гариза тапшыручының Ф.И.О. (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны адресы

_______________________________________

_______________________________________

элемтә өчен телефон, e-mail

Башлангыч гомуми белем бирүнең укыту программалары буенча кечерәк яшьтә укытуга _______________________________________________________________

(белем бирү оешмасының атамасы)

баламны кабул итүегезне үтенәм ______________________________________

_______________________________________________________________

(Ф.И.О. (соңгысы – булган очракта), туу датасы).

Гаризага беркетәм:

ата-ананың (законлы вәкилнең) шәхесен раслый торган документ;
бала туу турында таныклыкның күчермәсе;
сәламәтлек ягыннан белем алу өчен каршылыклар булмавын раслый торган «Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү учреждениеләре, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре, балалар йортлары һәм интернат мәктәпләре өчен баланың медицина картасы» 026/у-2000 номерлы форма (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Мәгариф учреждениеләре өчен баланың медицина картасын раслау турында» 2000 елның 3 июлендәге 241 номерлы боерыгы).

| ____________________ | ____________________ | ____________________ |
|---|---|---|
| көн, ай, ел | имза | имзаны шәрехләү |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә укытуга рөхсәт бирү тәртибенә

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына өлкәнрәк яшьтә башлангыч гомуми белем бирүнең укыту программалары буенча укытуга балаларны кабул итүгә рөхсәт алуга
гариза формасы

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрына __________________

Гариза бирүченең Ф.И.О. (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны адресы

_______________________________________

_______________________________________

элемтә өчен телефон, e-mail

Башлангыч гомуми белем бирүнең укыту программалары буенча өлкәнрәк яшьтә укытуга _______________________________________________________________

(белем бирү оешмасының атамасы)

баламны кабул итүегезне үтенәм ___________________________________

_______________________________________________________________

(Ф.И.О. (соңгысы – булган очракта), туу датасы).

Гаризага түбәндәгеләрне беркетәм:

ата-ананың (законлы вәкилнең) шәхесен раслый торган документ;

бала туу турында таныклыкның күчермәсе;

«Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү учреждениеләре, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре, балалар йортлары һәм интернат мәктәпләре өчен баланың медицина картасы» 026/у-2000 номерлы формасы (гомуми белем бирү оешмасы директоры тарафыннан таныкланган күчермә).

| ____________________ | ____________________ | ____________________ |
|---|---|---|
| көн, ай, ел | имза | имзаны шәрехләү |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә укытуга рөхсәт бирү тәртибенә

3 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек
һәм контроль департаментына

Адрес:______________________________

кемнән ______________________________
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

______________________________
(шәхси мәгълүматлар субъектының ата-анасының (законлы вәкиле) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

телефон номеры, электрон почта адресы яки почта адресы:

______________________________

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, ______________________________________________________________
(шәхси мәгълүматлар субъектының ата-анасының (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы-булган очракта)

______________________________________________________________
(шәхси мәгълүматлар субъектының ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхесен раслый торган документы)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаментына шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (тапшыру, бирү, тарату) ризалык бирәм

______________________________________________________________
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы-булган очракта)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына баланы (балаларны) кечерәк яисә өлкәнрәк

яшьтә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укытуга рөхсәт бирелгәннән соң.

Эшкәртелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге:

1) шәхси белешмәләр: баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) элемтә өчен телефон; электрон почта адресы; бала туу турында таныклык белешмәләре; яшәү урынының адресы;

2) шәхси мәгълүматларның махсус категорияләре:

3) биометрик шәхси мәгълүматлар:

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирелгән шәхси мәгълүматлар белән гамәлләр исемлеге: шәхси мәгълүматлар җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), файдалану (шул исәптән тапшыру), аларны исемсезләштерү, блоклау, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә юкка чыгару.

Оператор шәхси мәгълүматны, шәхси мәгълүматларны эшкәртүнең автоматлаштырылган чараларын кулланып, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча да, эшкәртә.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү срогы: әлеге ризалык аңа кул куйган көннән алып шәхси мәгълүматларны язма рәвештә кире алган көнгә кадәр гамәлдә була.

| ______________________________ | ______________ | ______________ |
|---|---|---|
| (шәхси мәгълүмат субъектының ата-анасының (законлы вәкиленең) ФИО) | (имза) | (дата) |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә укытуга рөхсәт бирү тәртибенә

4 нче кушымта

.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы комиссиясенең Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә кабул итү мәсьәләсе буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау өчен утырыш

БЕРКЕТМӘСЕ

___________20___ ел

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эш итеп, комиссия составында:

_______________________________________________________________

(баланың ФИО (соңгысы – булган очракта) күрсәтелә)

______________________________ яшендә белем бирү программалары буенча белем алуга кабул итү мәсьәләсен ата-анасыны (законлы вәкиле) катнашында

_______________________________________________________________

(ата-ананың (законлы вәкилнең) ФИО күрсәтелә)

_______________________________________________________________,

(Оешманың атамасы күрсәтелә)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы оешмасына кабул итүен карады.

Түбәндәге нәтиҗәләр ясады:

Имзалар:

мөһер

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кечерәк яисә өлкәнрәк яшьтә укытуга рөхсәт бирү тәртибенә

5 нче кушымта

.

Хәбәр итү формасы

башлангыч гомуми белем бирүнең укыту программалары буенча кече яшьтә яки соңрак яшьтә баланы белем бирү оешмасына укытуга кабул итүгә рөхсәт бирүдән мотивлы баш тарту турында

Түбәндәге адрес буенча яшәүче:__________

___________________________________

___________________________________

ата-анага (законлы вәкилгә)

________________________________________

___________________________________,

ХӘБӘР

Мәгариф өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 маддәсендәге 1 пунктына таянып, гаризагызны һәм аңа беркетелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмасына алты яшь һәм алты ай тулмаган (яки сигез яшьтән өлкәнрәк) балагызны кабул итүгә түбәндәге сәбәпләр аркасында рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәр итәбез.

Комиссия рәисе, вазифа _____________ _____________________

имза имзаны шәрехләү